ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мирфатиха Закиева, д.47,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Мирфатыйх Зәкиев урамы, 47йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 4** **11 март 2016 ел**

*Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 7 октябрендәге «Конкурс (аукцион) комиссиясе составын раслау турында»гы 21 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында*

2015 елның 26 декабрендәге «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы 109-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, юстиция министрлыгының хокукый экспертиза бәяләмәсен карап, Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитетының 2015 елның 7 октябрендәге «Конкурс (аукцион) комиссиясе составын раслау турында»гы 21 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «һәм дәүләт милке чикләнмәгән» сүзтезмәсе нигезләмәсенең 1, 2 пунктларыннан төшереп калдырырга;

1.2. Аерым затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә, комиссия составыннан чыгарырга: Мөхәммәтов С.М. - Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет Палатасы рәисе (килешү буенча); комиссия составына кертергә: Мөхәммәтова Р.Г. - Ютазы муниципаль районының Финанс-бюджет Палатасы рәисе (килешү буенча).

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендында игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге электрон адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге электрон адрес буенча куярга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы:** **А.Г.Дәүләтгәрәев**

Зарипова Р.В.
4-21-34